ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

# «Халыкның санитария-эпидемиология иминлеге турында» Татарстан Республикасы Законының 3 статьясына үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2025 елның 11 июнендә
кабул ителде

**1 статья**

«Халыкның санитария-эпидемиология иминлеге турында» 2006 елның 20 июнендәге 42-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 3 статьясындагы 1 өлешенә (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2006, № 6 (I өлеш); 2012, № 3, № 7 (I өлеш); 2014, № 6 (II өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2019, № 2 (I өлеш); 2021, № 77 (I өлеш), № 93 (I өлеш); 2023, № 11 (I өлеш), аңа түбәндәге эчтәлекле абзац өстәп, үзгәреш кертергә:

«Халыкның санитария-эпидемиология иминлеге турында» 1999 елның 30 мартындагы 52-ФЗ номерлы Федераль законның $22^{1}$ статьясындагы 4 пунктының 1 пунктчасындагы өченче абзацында күрсәтелгән затлар, Татарстан Республикасы территориясендә медицина калдыкларын транспортировкалау, зарарсызландыру хезмәтләрен күрсәтүче затлар хакындагы белешмәләрне, шулай ук Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан һәм әлеге затлар тарафыннан медицина калдыкларын йогышсызландыру, зарарсызландыру гамәлгә ашырыла торган объектлар исемлеген «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтта урнаштыру.».

**2 статья**

Әлеге Закон 2025 елның 1 июленнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Рәисе

Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2025 ел, 25 июнь
№ 47-ТРЗ